**СОВЕТ АТАБАЕВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ЛАИШЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

422635 Лаишевский район,
село Атабаево,ул.Молодежная , д.1
тел,факс: 8(84378)-4-87-41
Atab.La@tatar.ru

**АТАБАЙ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ ЛАЕШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**

422635 Лаеш районы, Атабай авылы
ул.Яшьлэр урамы, 1нче йорт
тел, факс: 8(84378)-4-87-41
Atab.La@tatar.ru

**2023 елның 16 октябре** **146 номер**

# КАРАР

## Атабай авыл җирлеге Советының «Атабай авыл җирлеге территориясендә көнкүреш калдыкларын һәм чүп-чарны җыю һәм чыгаруны оештыру тәртибе турында» 2012 елның 12 июнендәге 44 номерлы карарына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү хакында

РФ Хөкүмәтенең 2020елның 11 июлендәге № 1036 номерлы " "Россия Федерациясе Хөкүмәтенең норматив хокукый актларының һәм норматив хокукый актларының аерым нигезләмәләренең үз көчләрен югалтуын тану турында, мәҗбүри таләпләре булган федераль башкарма хакимият органнарының кулланучылар хокукларын яклау өлкәсендә федераль дәүләт күзәтчелеген гамәлгә ашырганда тикшереп тору чараларын уздырганда үтәлеше бәяләнгән норматив хокукый актларын юкка чыгару турында" карары нигезендә, Атабай авыл җирлеге Советы карар чыгарды:

1. Атабай авыл җирлеге Советының «Атабай авыл җирлеге территориясендә көнкүреш калдыкларын һәм чүп-чарны җыю һәм чыгаруны оештыру тәртибе турында» 2012 елның 12 июнендәге 44 номерлы карарына, яңа редакциядә, үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертергә.

- 10.16 пункты үз көчен югалткан дип танырга.

2. Әлеге карарны Интернет телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru. веб–адресы буенча һәм интернет телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре Порталында урнаштырылган Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының рәсми сайтында-http://laishevo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны җирләрдән файдалану, экологик иминлек һәм җирлек Советын төзекләндерү мәсьәләләре буенча комиссиягә йөкләргә.

**Башлык-Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Атабай авыл җирлеге Советы рәисе** **Л.Р.Хәлилова**